**Республика Татарстан**
**Старо-Имянское сельское**
**поселение Сармановского**
**муниципального района**

**Татарстан Республикасы**
**Сарман муниципаль**
**районынын Иске Имән**
**авыл жирлеге**

**КАРАР**
**21.06.2018**

**КАРАР**
**№ 87**

Советның 2007 елның 17 июлендәге 11 номерлы карары белән расланган Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлегендә гавами тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 29 декабрендәге 455-ФЗ номерлы Федераль законы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Иске Имән авыл җирлеге Советы карар итте:

1. 9.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
   "9.4. Җәмәгать фикер алышулар яисә гавами тыңлауларда катнашучыларны җәмәгать фикер алышуларында яисә гавами тыңлауларда катнашу өчен тигез мөмкинлекләр белән тәэмин итү максатларында җәмәгать фикер алышулары яисә гавами тыңлаулар үткәргәндә торак пункт территориясе өлешләргә бүленергә мөмкин."
2. 9.5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
   "9.5. Җәмәгать фикер алышулар яисә гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә басылып чыккан көнгә кадәр муниципаль берәмлек уставы һәм (яисә) муниципаль берәмлек вәкиллекле органының норматив хокукый акты белән билгеләнә һәм кимендә бер ай һәм өч айдан артыграк була алмый.
3. 11.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
   "11.2. Җәмәгать фикер алышулар яисә гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә басылып чыккан көнгә кадәр аларны уздыру турында муниципаль берәмлек халкына хәбәр иткән көннән алып муниципаль берәмлек уставы һәм (яисә) муниципаль берәмлек вәкиллекле органының норматив хокукый акты белән билгеләнә һәм кимендә бер айдан һәм өч айдан артыграк була алмый."
4. 12.2 пунктта «Комиссия» сүзен «Җәмәгать фикер алышулар яисә гавами тыңлаулар оештыручы» сүзләренә алмаштырырга, «бирү мәсьәләсе буенча

гавами тыңлаулар» сүзләрен «бирү турында карар проекты буенча җәмәгать фикер алышулар яисә гавами тыңлаулар» сүзләренә алмаштырырга.

5. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы» (PRAVO.TATARSTAN.RU) хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Сарман муниципаль районының рәсми сайтында Интернет челтәрендә урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Иске Имән авыл җирлеге
Советы рәисе Р.Ә.Исламова